**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«__05__» ____06_____ 2024 ел.** **№ ___107___**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының «Азнакай муниципаль районының «Административ хуҗалык идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмә» 2018 елның 08 маендагы 99 номерлы карары белән расланган Азнакай муниципаль районының “Административ хуҗалык идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсендәге эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында»гы 2024 елның 29 апрелендәге 287 номерлы карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы «Бюджет өлкәсендә эшләүче аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында” карары, социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм Азнакай муниципаль районының «Административ хуҗалык идарәсе” муниципаль бюджет учреждениесе хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне тәртипкә салу максатларында, карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының «Азнакай муниципаль районының «Административ хуҗалык идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмә» 2018 елның 08 маендагы 99 номерлы карары белән расланган Азнакай муниципаль районының «Административ хуҗалык идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.6 пунктындагы беренче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Муниципаль учреждение җитәкчесенең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре муниципаль берәмлекләрдә Татарстан Республикасы бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмасының структур бүлекчәсе җитәкчесенең вазыйфаи окладлары сәркатибенә вазыйфаи оклады

күләменә тапкырлар исәпләп чыгарыла, ул 13 323 сум 00 тиен тәшкил итә.»;

2.3 пунктының 4 пунктчасында «15 процент» сүзләрен «37 процент» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктының 4 пунктчасында «15 процент» сүзләрен «37 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов